УТВЕРЖДАЮ:

Директор МБОУ «СОШ с.Сарлы».

# Сарлы авылы
# муниципаль гомуми урта белем бирү мәктәбе китапханәсенең еллык эш планы

2023-2024 нче уку елы

# 2022-2023 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА АНАЛИЗ

### *1.* 2022-2023 нче уку елының санлы күрсәткечләре

Китап укучылар саны

| Укучылар Саны | | Укытучылар саны | | Башка хезмәткәрләр |
|---|---|---|---|---|
| Барлык укучылар | Китапханәгә язылганнар | Барлык укытучылар | Китапханәгә язылганнар | |
| *53* | 53 | 17 | 17 | 6 |

### *2.* 2023 нче елның 1 сентябренә китапханә фонды

<table>
<tr><td rowspan="2">Барлыгы</td><td rowspan="2">Методик әсбаплар</td><td rowspan="2">Справ.</td><td colspan="2">Матур әдәбият<br>*1298*</td><td colspan="2">Дәреслекләр</td><td rowspan="2">Электр.мульт. дәреслекләр</td></tr>
<tr><td>Р.т</td><td>Т.т</td><td>Ф.</td><td>Р.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">2823</td><td rowspan="2">40</td><td rowspan="2">93</td><td rowspan="2">*670*</td><td rowspan="2">*628*</td><td>916</td><td>284</td><td rowspan="2"></td></tr>
<tr><td colspan="2">1200</td></tr>
</table>

**1. Китапханә үзенең эшендә :-** мәктәп китапханәсенең эшен укыту- тәрбия планына нигезләнеп укучыларга эстетик тәрбия бирү юнәлешендә оештыру;

- барлык укучыларның 100% китап укуларына ирешү;

-укучыларда китап уку культурасы тәрбияләү;

-китапны мөстакыйль сайлый белү;

-газета-журналлар укый белергә өйрәтүне;

-укучылар белән индивидуаль эшләүне **бурыч** итеп куйды.

**2. Китапханә шулай ук:-** китапханәдәге һәр китапны үзенең укучысына җиткерүне;
- китапханә эшен төп документлар ярдәмендә алып баруны;
- китап пропагандалау аша укытучыларга укыту-тәрбия эшен оештыруда, үз белемнәрен күтәрүдә ярдәм итүне;
- яңа кайткан китаплар ярдәмендә китапларга күзәтү үткәрүне;
- һәр укучының ничек укуы, ел буе китапханәгә ни дәрәҗәдә йөреше турында системалы рәвештә класс җитәкчеләренә җиткерү;
- башлангыч класс укучыларын китапханәгә экскурсия оештыру, китапханәнең төп кагыйдәләре, уку культурасын тәрбияләү турында әңгәмәләр үткәрү;
-китапханә эше, китап фонды, китапханәгә алына торган газета-журналлар, эчке кагыйдәләр, китапны ничек саклап тоту турында класс сәгатьләрендә әңгәмәләр үткәрүне үз эченә алды.

Укучыларның китап укуларына юнәлеш бирү, аларның нәрсә белән күбрәк кызыксынуларын, ничек укуларын өйрүнү максатында укучылар белән әңгәмәләр үткәрелде.

Укучыларны рус һәм татар әдәбияты буенча, шулай ук башка фәннәрдән класстан тыш уку өчен тәкъдим ителә торган китаплар белән тәэмин ителде.

Укучыларның китап укуына анализ ясап, класс җыелышларында әти-әниләргә җиткерелде.

Китапханәгә укучыларның йөреше канәгатьләнерлек.Укылыш: 1укучыга якынча 15 китап . Мәктәп китапханәсеннән мәгълүматлар эзләүдә укытучыларга,әти-әниләргә,укучыларга методик ярдәм күрсәтелде. Китаплар һәм периодик басмалар белән танышу өчен укучыларга , укытучыларга шартлар тудырылды. Һәр кайткан дәреслек белән фән укытучылары таныштырып барылды. Яңа уку елына региональ һәм федераль дәреслекләргә заказлар бирелде.

Укучылар белән китап уку культурасы турында дәресләр, библиографик дәресләр, әдәби әсәрләр турында фикер алышу, китап белән ничек эшләү турында әңгәмәләр, әдәби сәгатьләр үткәрелде.Китапны саклау буенча буклетлар ясалып таратылды һәм китап торышы буенча рейдлар уздырылды.

Мәктәп күләмендәге чараларны үткәрүдә катнаштык :
- башлангыч сыйныфлар һәм фән атналыклары;
- 1  сентябрь - белем көне;
- Әниләр бәйрәме;өлкәннәр көне,укытучылар көне,уңыш бәйрәме,8-март,23 февраль
- бердәм мәдәният дәресе;
- “Сөмбелә”, Яңа ел, “Соңгы  кыңгырау” бәйрәмнәре;
- мәрхәмәтлелек айлыгында катнашу;
- иҗтимагый акцияләр: наркомания һәм тәмәкегә каршы көрәш көне һ.б.;
- мәктәп стендларын бизәүдә булышу.
Укытучылар һәм эти-әниләр белән үткәрелә торган түбәндәге эшләрдә катнашып:
- педагогик киңәшмә утырышларында чыгыш ясау;
-  яңа кайткан әдәби, фәнни, укыту-методик китапларга һәм дәреслекләргә күзәтү;
- китапханә эше һәм аны планлаштыру турында отчетлар;
-китап күргәзмәләре ясау;

**“Октябрь ае- халыкара мәктәп китапханәләре айлыгы”** дип игълан ителде.Айлыкның беренче көннәрендә 1 сыйныф укучылары китапханәбездә экскурсиядә булды.

“Китапка икенче гомер” акциясе ай буе дәвам итте. **«Китапка икенче гомер»** акциясендә актив катнашучылар күп булмады.

12.09.2022 - “Китап төзелеше, китапны ничек укырга?” темасына 2-3 классларда библиографик дәрес булды. 20.09.2022 башлангыч сыйныфлар белән “Бердәм культура дәресе” уздырдык һәм укучыларга “Мәдәни көндәлекләр” тапшырылды. 25.10.2022 “Китаплар сакланышы буенча 5 сыйныф укучылары белән мәктәп күләмендә рейд уздырдык. Рейд нәтиҗәләре белән мәктәп күләмендә уздырылган линейкада таныштырылды. Классларга “Яшә китап” буклетлары таратылды.

21 октябрь көнне 4 сыйныф укучылары белән  “Китап барлыкка килү тарихы ” исем астында библиографик дәрес үткәрде. Бу дәрестә укучыларны китапханәче китапның барлыккы килу тарихы белән таныштырды. Беренче китаплар кайда һәм  нинди материаллардан эшләнгәнен  белделәр.Укучылар шулай ук китапның безне һәрчак яхшыга гына өйрәтүен һәм тормышыбызны нурлы итүен, белемле, әдәпле, акыллы киңәш бирүен, хезмәт сөючән, күркәм кеше булып үсәргә ярдәм итүен, туган илне сөяргә, хезмәт яратырга, авыр вакытта югалып калмаска өйрәтүен аңладылар.

22 октябрьдә башлангыч сыйныф укучылары арасында”Әкиятләр иленә кунакка”исеме астында әдәби викторина уздырылдым.

23 октябрь көнне **“Яшә китап”**акциясе дә уздырылды.2-4 сыйныф укучылары  “китап докторлары” булып , мәктәп китапханәсендәге китапларны дәвалауда бик теләп катнаштылар. Алар бу акциядә ярдәмгә могтәҗ булган 18 китапны ремонтладылар.

“Минем яраткан китабым”рәсем конкурсында да укучылар актив катнашты. Айлык тәмамлангач,иң активларга һәм җиңүчеләргә грамоталар тапшырылды.

Районда уздырылган китапханәчеләрнең  “Иң яхшы китапханә газетасы “, “Иң яхшы китап күргәзмәсе “конкурсында  катнашып яхшы нәтиҗәләргә лаек булдым.

Юбилярлар һәм истәлекле даталар уңаеннан китап күргәзмәсе, төрле чаралар оештырылды.

Шулай ук “Сәламәтлек- зур байлык”, “Әниләр турында”,”Хокуклар һәм бурычлар ”  ,”Балаларга сугыш турында” исеме астында китап күргәзмәләре оештырылды.

21 февраль “Туган тел көне” билгеләп үтелде. 3-6 нче сыйныф укучылары туган тел көненә багышланган викторинада катнаштылар.

Тематик китап  күргәзмәләре дә эшләнде. Сентябрнең беренче атнасында-“Юлда йөрү кагыйдәләрен төгәл утә!”Неделя  безопасности ПДД” атналыгы кысаларында китап күргәзмәсе оештырылды.“РФ конституциисе көне”,”Батырлык”айлыгында “Алар Ватан сагында “китап күргәзмәсе, Космонавтика конедә, география атналыгында “Космоска  таба” күргәзмәсе оештырылды һәм шунда ук балалар ясаган рәсемнәр дә урын алды.Экологик темага **“Кошлар –безнең дусларыбыз ”**- стена газетасы чыгарылды.Башлангыч сыйныфлар атналыгы кысаларында күп кенә чаралар уздырылды.”Безнең яраткан китаплар”күргәзмәсе ясалды.”Әдәби викторина”укучыларда бик  кызыклы узды.

Мәрхәмәтлелек атналыгында таушалган китаплар яңартуда да укучылар бик теләп катнашты.  Ата-аналар җыелышында укучыларның дәреслекләр белән тәэмин ителеше буенча чыгыш ясалды.Укытучылар да үз вакытында газета – журналларга язылып киләләр.

Педагог – библиотекарь                    Гатиятова А.З.

# 2023-2024 уку елына китапханәнең эш планы

## Төп бурычлар:

**1. Китапханә үзенең эшендә :**

- укыту-тәрбия процессына якыннан торып булышлык күрсәтүне;
- белем дәрәҗәсен үстерүдә ярдәм итүне;
- укучылар белән эшләүнең төрле форма һәм ысулларын камилләштерүне ;
- информацион – библиографик эшне яхшыртуны;
- авыл китапханәсе белән эшне тыгыз бәйләп алып баруны;
- китап күргәзмәлек эшләрен активлаштыруны;
- укучылар белән индивидуаль эшләүне **бурыч** итеп куя.

**2. Китапханә шулай ук:**

- китапханәдәге һәр китапны үзенең укучысына җиткерүне;
- дәреслекләрне класслап урнаштыруны;
- матур әдәбият китапларын аерым класс укучыларына яраклаштырып урнаштыруны;
- китапханә эшен төп документлар ярдәмендә алып баруны;
- китап пропагандалау аша укытучыларга укыту-тәрбия эшен оештыруда, үз белемнәрен күтәрүдә ярдәм итүне;
- яңа кайткан китаплар ярдәмендә китапларга күзәтү үткәрүне;
- һәр укучының ничек укуы, ел буе китапханәгә ни дәрәҗәдә йөреше турында системалы рәвештә класс җитәкчеләренә җиткерү;
- укуы начар булган укучылар белән өстәмә эшләүне ныгытуны;
- башлангыч класс укучыларын китапханәгә экскурсия оештыру, китапханәнең төп кагыйдәләре, уку культурасын тәрбияләү турында әңгәмәләр үткәрү;
- китапханә эше, китап фонды, китапханәгә алына торган газета-журналлар, эчке кагыйдәләр, китапны ничек саклап тоту турында класс сәгатьләрендә әңгәмәләр үткәрүне үз эченә ала.

**УКУЧЫЛАРГА ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮНЕ ОЕШТЫРУ.**
**УКУЧЫЛАРНЫҢ КИТАП УКУЫНА ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ**

- Укучыларның китап укуларына юнәлеш бирү, аларның нәрсә белән күбрәк кызыксынуларын, ничек укуларын өйрүнү максатында укучылар белән әңгәмәләр үткәрү.
- Укучыларны рус һәм татар әдәбияты буенча, шулай ук башка фәннәрдән класстан тыш уку өчен тәкъдим ителә торган китаплар белән тәэмин итү.
- Чирек саен иң күп китап укучыларны ачыклау һәм чыгышларда яктырту.
- Укучыларның китап укуына анализ ясап, класс җыелышларында әти-әниләргә җиткерү.

**Сентябрь аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Мәктәпкә килгән һәр яңа укучыны китапханә һәм андагы тәртипләр белән таныштыру. | даими | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | Яңа уку елында укытылачак дәреслекләрнең исемлеген булдыру.<br>-“Таныш булыгыз- яңа дәреслек” – китап күргәзмәсен яңарту.<br>-“Юлда йөрү кагыйдәләрен төгәл утә!”Неделя безопасности ПДД” атналыгы кысаларында китап күргәзмәсе<br>А.Алишның тууына 115 ел.<br>09.09.23-195 лет Толстой Лев Николаевич | даими<br><br>20-24.09<br><br>15.09.2023 | Китап-че | 1-10сыйныф<br><br>1-11сыйныф<br><br>1-3 кл.<br>4-9 кл., |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | а) Яна килгән укучыларны (1 сыйныф)китапханә белән таныштыру.<br>б) Китап төзелеше, китапны ничек укырга? | 17.09 | Китап-че | 1-3 сыйныф |
| 4. Хәрби патриотик тәрбия | “Минем кече Ватаным”.Әдәби документаль китапларга күзәтү ясау. | 23.09 | Китап-че | |
| 5. Педагогик коллектив белән эш | Яңа кайткан дәреслекләр белән укытучыларны таныштырып бару. | 02.09 | Китап-че | |
| 6. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>б) Искерү сәбәпле гамәлдән чыккан китапларны учеттан төшерү.<br>в) 2023-24нче уку елы өчен , яңа кайткан уку әсбапларын, дәреслекләрне ЭФУЛ га урнаштыру,акт нигезендә җитмәгән дәреслекләрне район мәктәпләре китапханәләреннән алып тулыландыру.<br>Терроризм һәм экстремистик эшчәнлеккә карата закон бозуларны кисәтү максатыннан, китапханә фондына инвентаризация үткәрү. | даими | Китап-че | |
| 7. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | а ) Китапханә яңалыклары белән танышып бару.<br>б) Мәктәп китапханәчеләре семинарында катнашу.<br>в) 2024 нче елның 1 нче яртыеллыгы өчен гәҗит – журналларга язылуны оештыру. | даими | Китап-че | |

**Октябрь аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | а) Яңа килгән укучыларны китапханәгә язу. | даими | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау,**китап күргәзмәсе.** | - Яңа кайткан китапларны укучыларга тәкъдим итү.<br>130 лет со дня рождения русской поэтессы, прозаика и драматурга Марины Ивановны Цветаевой (1892–1941).<br>120 лет со дня рождения русского писателя Евгения Андреевича Пермяка (н. ф. Виссов) (1902–1982). «Волшебные краски», «На все цвета радуги», «Памятные узелки» | Даими<br><br>2.10 | Китап-че<br><br>учителя литературы | <br><br>5-11 сыйныф |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Китап барлыкка килү тарихы (4 нче сыйныф | 8.10 | Китап-че | 4 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | Укучыларның сыйныфтан тыш укуларына юнәлеш бирү, китаплар тәкъдим итү. | даими | Китап-че | 5 сыйныф<br>1-11сыйныф |
| 5. Хәрби патриотик тәрбия | Рәсәйдә репрессия корбаннарын искә алу көне. “Хәтер” көнен билгеләп үтү<br>Хокук бозуларны кисәтү максат ыннан, “Минем хокукларым” дигән китап күргәзмәсе. | 15.10<br>30.10 | Китап-че | <br><br>1-11 сыйныф |
| 6. Масса күләм чаралар | «Китапка икенче тормыш бүләк ит!» акциясен оештыру(күргәзмә ясау) . | Сентябрь-октябрь | Китап-че | 1-11 сыйныф |
| 7. Педагогик коллектив белән эш | а)яңа кайтка н китапларга күзәтү ясау.<br>б) Яңа кайткан китапларны укучыларга тәкъдим итү. | даими | Китап-че | |
| 8. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу.<br>б) 2023-2024нче уку елы өчен дәреслекләрнең электрон фонды (ЭФУЛ)буенча, акт нигезендә класслар һәм фәннәр буенча җитмәгән дәреслекләрне район мәктәпләре китапханәләреннән алып тулыландырырга. | | Китап-че | |

**Ноябрь аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Беренче татар китабы басылып чыгу тарихы.(стенд) | ноябрь | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | 4 ноябрь- халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтү;<br>6 ноябрь Татарстан Республикасы Конституциясе коне<br>**24.11.** – ана көне ,аналар турында эсэрлэр.<br>23.11.23-115 лет Носов Николай<br>205 лет со дня рождения Ивана Сергеевича Тургенева, писателя (1818-1883)<br>Гадел Кутуйның тууына 120 ел | 04.11<br>20.11<br>27.11.23 | Китап-че<br>Китап-че, учителя литературы | |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Иң матур китапханәләр | 18.11 | Китап-че | 5 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | а) Укучыларның сыйныфтан тыш укуларына юнәлеш бирү, китаплар тәкъдим итү. | | Китап-че | 5-7 сыйныф |
| 5. Китапханә активы белән эш | а) Дәреслекләрнең торышын тикшерү.<br>б)Китаплар ремонтлауны оештыру. | Даими | Китап-че | |
| 6. Педагогик коллектив белән эш | Яңа кайткан методик кулланмалар һәм газета журналлар белән таныштыру. Методик берләшмә җитәкчеләре белән 2024-25 уку елы өчен федераль китапларга һәм методик ярдәмлекләргә заявка эзерләү. | Даими | Китап-че | |
| 7. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>б) Искерү сәбәпле гамәлдән чыккан китапларны учеттан төшерү. | Даими | Китап-че | |
| 8. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | - «Школьная библиотека», «Библиотека» электрон журналларын уку.<br>- китапханә эше турында приказлар,хатлар, инструкцияләр белән танышып бару | даими | Китап-че | |

**Декабрь аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | “Белем китаптан башлана” Башлангыч сыйныфларда яңа кайткан китапларга күзәтү оештыру. | | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | **1.12.** – Бөтендөнья СПИДка каршы көрәш көне;<br>**9 .12.** – Ватан геройлары көне,<br>коррупциягә каршы көрәш көнен билгеләү.“Без коррупциягә каршы!” - күргәзмә рәсем конкурсы, китапханәгә кайткан яңа китапларга күзәтү ясау<br>12.12.23-95 лет Айматов Чингиз Торекулович<br>Шамил Усмановның тууына 125 ел | 2.12<br>12.12<br>0.12 | китапх-че<br>Учителя литературы | 9-11 сый |
| 3.Библиографик белем пропагандалау | Яшьләр өчен газета, журналлар. | даими | Китап-че | 6 сыйныф |
| 6. Педагогик коллектив белән эш | Фән атналыкларында катнашу. | даими | Китап-че | |
| 7. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>б) Уку фондының сакланышы буенча эш (классларда рейдлар үткәрү, нәтиҗәләр чыгару). | даими | Китап-че | |
| 8. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | Китапханә яңалыклары белән танышып бару;<br>Мәктәп китапханәчеләренең район семинарларында катнашу. | даими | Китап-че | |

**Январь аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Башлангыч сыйныф укучылары белән “Минем яраткан китабым” дип исемләнгән әңгәмә үткәрү | 16.01 | Китап-че | 2-4 сый |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | **120 лет со дня рождения Аркадия Петровича Гайдара, писателя (1904-1941)** | 16.01<br>25.01 | Китап-че | 2-11 сый |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Библиографик эзләнүче | 13.01 | Китап-че | 7 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | Укучыларның сыйныфтан тыш укуларына юнәлеш бирү, китаплар тәкъдим итү. | Даими | Китап-че | 2-4 сый. |
| 5. Хәрби патриотик тәрбия | 27 января- День воинской славы России.День снятия блокады Ленинграда (1944). | 27.01 | Китап-че | 11 сый |
| 6. Китапханә активы белән эш | Тәнәфес вакытларында, класс сәгатьләрендә, класс җыелышларында, әти-әниләр җыелышында – телдән реклама ясау. | Даими | Китап-че | |
| 7. Педагогик коллектив белән эш | Фән атналыкларында катнашу. | | Китап-че | |
| 8. Китапханә фонды белән эш | Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>Искерү сәбәпле гамәлдән чыккан китапларны учеттан төшерү. | Даими | Китап-че | |
| 9. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | Иң яхшылардан саналган мәктәп китапханәчеләренең тәҗрибәләрен кулланып үз белемеңне күтәрү өстендә эшләү. | Даими | Китап-че | |

**Февраль аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Минем яраткан китабым" дигән темага 1нче сыйныф укучылары белән әңгәмә. | 24-29 .02 | Китап-че | 1 сыйныф |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | "Алар Ватан сагында " китап күргәзмәсе оештыру.<br>130 лет со дня рождения Виталия Валентиновича Бианки, русского детского писателя и природоведа, автора рассказов и сказок о животных (1894-1959)<br>255 лет со дня рождения Ивана Андреевича Крылова, русского писателя, баснописца (1769-1844) | 4.02<br><br>11.02 | <br><br>Китап-че | 2-11сыйныф |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Китап белән ничек эшләргә? | Даими | Китап-че | 8 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | "Как писать отзыв" дигән темага 4нче сыйныф укучылары белән әңгәмә. | 1.02 | Китап-че | 4 сыйныф |
| 5. Хәрби патриотик тәрбия | Герой шагыйрь Муса Җәлил һәм Җәлилчеләрне искә алу.<br>15 февраля 1906 - 1944 | 14.02 | Китап-че | 5-11 сыйныфлар |
| 6. Китапханә активы белән эш | Дәреслекләр торышын тикшерү. | Даими | Китап-че | |
| 7. Педагогик коллектив белән эш | Методик берләшмә җитәкчеләре белән 2023-24 уку елы өчен федераль китапларга һәм методик ярдәмлекләргә заявка бирү. | | Китап-че | |
| 8. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>б) Искерү сәбәпле гамәлдән чыккан китапларны учеттан төшерү. | Даими | Китап-че | |
| 9. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | Китапханә яңалыклары белән танышып бару. | Даими | Китап-че | |

**Март аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Башлангыч сыйныф укучыларына табигать турында китаплар тәкъдим итү. | 25.03 | Китап-че | 2-4 сыйныф |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | а) Яңа кайткан китапларны укучыларга тәкъдим итү.<br>б )21 март –Бөтендөнья Җир көне<br>200 лет со дня рождения Константина Дмитриевича Ушинского, педагога и писателя (1824-1871)<br>100 лет со дня рождения Юрия Васильевича Бондарева, писателя (1924 г.р.) | 5.03 | Китап-че | 7-8 сыйныфлар |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | План, конспект төзергә өйрәтү. | даими | Китап-че | 9 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | Норкоманиягә һәм норкобизнеска каршы халыкара көрәш көне.<br>Бөтендөнья туберкулезга каршы көрәш көне. | 15.03 | Китап-че | 10 сый |
| 5. Хәрби патриотик тәрбия | Фронтовик язучыларның әсәрләреннән китап күргәзмәсе. | 12.03 | Китап-че | 10 сый |
| 6. Китапханә активы белән эш | а) Китап укучыларны барлау.<br>б) Китап ремонтлауны оештыру. | даими | Китап-че | |
| 7. Педагогик коллектив белән эш | Фән атналыкларында катнашу . | | Китап-че | |
| 8. Китапханә фонды белән эш | а) Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>б) Таушалган китапларны ремонтлауны оештыру. | даими | Китап-че | |
| 9. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | а ) Китапханә яңалыклары белән танышып бару.<br>б) Башка мәктәп китапханәчеләренең эш тәҗрибәсен өйрәнү, эштә куллану. | даими | Китап-че | |

**Апрель аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Халыкара балалар китабы көнен билгеләп үтү.<br>Халыкара һәйкәлләр һәм тарихи урыннар көне. | 2.04<br><br>1.04 | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау, китап күргәзмәсе. | Яңа кайткан китапларны укучыларга тәкъдим итү<br>**2 .04.** – Бөтенхалык балалар китабы көнеХанс Кристиан Андерсен туган көн.<br>**7 .04.** – Бөтендөнья сәламәтлек көне<br>“Хуш киләсез, кошкайлар, безнең якын дускайлар” Кошлар көне уңаеннан укучыларга китаплар тәкъдим итү.<br>215 лет со дня рождения Николая Васильевича Гоголя, русского писателя (1809-1852**)** | 1.04 | Китап-че | 2-5 сый |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Әдәби әсәрләрдән цитаталар сайлау һәм аларны файдалану | | Китап-че | 9 сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | Татар халкының бөек шагыйре Г. Тукайның туган көне уңанннан,” Тукай шигырьләренең сихри дөнясы” дип исемләнгән шигырь бәйрәме уздыру,иҗатына күзәтү ясау. | 27.04 | Китап-че | 2-10 сый |
| 5. Китапханә активы белән эш | Укучыларның китап укуларына анализ ясау, дәреслекләрнең тотылышын тикшерү буенча рейдлар үткәрү. | 30.04 | Китап-че | |
| 6. Педагогик коллектив белән эш | Яңа кайткан китапларга күзәтү ясау, укытучыларга тәкъдим итү. | даими | Китап-че | |
| 7. Китапханә фонды белән эш | Яңа кайткан китапларны учетка алу;<br>2023-2024 нче уку елына дәреслек-ләргә инвентаризация үткәрү. | | Китап-че | |
| 8. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | Китапханә яңалыклары белән танышып бару.<br>2024 нче елның 2 нче яртыеллыгы өчен гәҗит-журналларга язылуны оештыру. | даими | Китап-че | |

**Май аена эш планы.**

| Эш төре | Эчтәлек | Үткәрү вакыты | Җаваплы | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. Укучыларны китапханәгә тарту | Җәйге каникул чорында уку өчен укучыларга китаплар тәкъдим итү. | 26.05 | Китап-че | |
| 2. Китап пропагандалау,китап күргәзмәсе. | Выставка-обзор «Детям о войне». | 22.05 | Китап-че | |
| 3. Библиографик белем пропагандалау | Белешмә әдәбият, сүзлекләр, энциклопедияләр. | Даими | Китап-че | 11сыйныф |
| 4. Сыйныфтан тыш уку белән идарә итү | 9,11нче сыйныф укучыларына экзаменнарга әзерләнү чорында методик ярдәм күрсәтү. | Даими | Китап-че | |
| 5. Хәрби патриотик тәрбия | Бөек Җиңүнең 79 еллыгынакитап күргәзмәсе оештыру | 6.05 | Китап-че | 8-10 сыйныфлар |
| 6. Китапханә активы белән эш | а) Дәреслекләр кабул итүне оештыру.<br>б) Әҗәтле укучыларны барлау. | 25.05 | Китап-че<br>Сый. җит | |
| 7. Педагогик коллектив белән эш | Яңа кайткан китапларга күзәтү ясау. | Даими | Китап-че | |
| 8. Китапханә фонды белән эш | Искерү сәбәпле гамәлдән чыккан китапларны учеттан төшерү. Укучылардан килгән дәреслекләрне фондка урнаштыру.2023-2024нче уку елы өчен дәреслекләрнең электрон фонды (ЭФУЛ)буенча, акт нигезендә класслар һәм фәннәр буенча җитмәгән дәреслекләрне район мәктәпләре китапханәләреннән алып тулыландырылган дәреслекләрне тапшыру. | | Китап-че | |
| 9. Үз белемеңне күтәрү өстендә эш | Китапханә яңалыклары белән танышып бару. | | Китап-че | |